**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 12 апрель № 219

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының салымнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерү турында

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән дәүләт мөлкәтеннән нәтиҗәле файдалану һәм Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының салымнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының салымнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибе турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына ел саен 1 сентябрьгә кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына узган финанс елы өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының салымнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерү турында, шулай ук узган еллар йомгаклары буенча әлеге түләүләр буенча бурычларны түләү хакында мәгълүмат тапшырырга.

3. «Татлизинг» дәүләт унитар предприятиесенә мөнәсәбәтле әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматны тапшыру Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 ел йомгаклары буенча дәүләт унитар предприятиеләре табышының салымнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган бер өлешен Татарстан Республикасы

бюджетына күчерү турында» 2016 ел, 12 март, 136 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\219.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 12 апрель, 219 нчы карары белән расланды

# Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының салымнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының салымнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының салымнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган бер өлешен (алга таба – табышның бер өлеше) күчерү механизмын билгеләү максатларында эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасының финанс елын табыш белән тәмамлаган барлык дәүләт унитар предприятиеләренә кагыла.

1.3. Табышның бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерүне тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы («Татлизинг» дәүләт унитар предприятиесенә мөнәсәбәтле – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы) гамәлгә ашыра.

## 2. Табышның Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле өлеше күләме

2.1. Әлеге Нигезләмә максатларында, агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле узган финанс елы өчен табышның өлеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт унитар предприятиеләре, Татарстан Республикасы өлеше 100 процент булган ачык акционерлар җәмгыятьләре җитәкчеләре һәм ачык акционерлар җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарындагы дәүләт вәкилләре хисаплылыгы тәртибен раслау турында» 2000 ел, 26 сентябрь, 691 нче карары белән расланган Дәүләт унитар предприятиеләре, Татарстан Республикасы өлеше 100 процент булган ачык акционерлар җәмгыятьләре җитәкчеләре һәм ачык акционерлар җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарындагы дәүләт вәкилләре хисаплылыгы тәртибе нигезендә дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырыла торган узган финанс елы өчен дәүләт унитар предприятиесенең бухгалтерлык хисаплылыгы һәм Татарстан

Республикасы дәүләт унитар предприятиесе җитәкчесе хисабы мәгълүматлары нигезендә билгеләнә.

2.2. Табышның Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле өлеше күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында билгеләнә.

### 3. Табышның бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына түләү вакыты һәм шартлары

3.1. Табышның бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерү дәүләт унитар предприятиеләре тарафыннан тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында билгеләнгән вакытта бюджет классификациясенең тиешле коды буенча гамәлгә ашырыла.

3.2. Табышның бер өлешен күчерүне гамәлгә ашыру өчен реквизитлар Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан агымдагы елның 1 маена кадәр (1 майны да кертеп) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә җиткерелә.

### 4. Табышның бер өлешен күчерү өчен билгеләнгән вакытларны бозган өчен җаваплылык

4.1. Дәүләт унитар предприятиесе җитәкчесе табышның бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерү өчен билгеләнгән вакытларны үтәү өчен үзе җаваплылык тота.

4.2. Дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре табышның бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына күчерү өчен билгеләнгән вакытларны бозган очракта Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы («Татлизинг» дәүләт унитар предприятиесенә мөнәсәбәтле – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы) законнар һәм хезмәт шартнамәсе нигезендә әлеге җитәкчеләргә мөнәсәбәтле дисциплинар характердагы чаралар күрә.

---